| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ИЖ-БОБЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИЖ-БУБЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 Иж-Бубый авылы № 17

«2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнары, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Прокуратурасының 06.03.2024 елның 02-08-02-2024/50 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча өстәргә:

«1.1. Әлеге муниципаль программа индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы физик затларга карата кагыла».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының

рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р.Р.Ваһапов